**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 19 июнь № 392

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге формада белем алучы студентларга дәүләт академик стипендиясен, студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 121 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге формада белем алучы студентларга дәүләт академик стипендиясен, студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясен билгеләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге формада белем алучы студентларга дәүләт академик стипендиясен, студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 121 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 18 октябрь, 755 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге формада белем алучы студентларга дәүләт академик стипендиясен,

студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендиясен билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 бүлекнең 2.2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Дәүләт социаль стипендиясе ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затлар, инвалид балалар, I һәм II төркем инвалидлар, бала чактан инвалид булган студентларга, Чернобыль АЭСында һәлакәт һәм башка радиация һәлакәтләре аркасында, Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган студентларга, хәрби хезмәт узган чорда алган хәрби имгәнү яки авыру аркасында инвалидлар һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары булган студентларга, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының эчке гаскәрләрендә һәм федераль дәүләт органнарында, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә, федераль башкарма хакимият органнары каршындагы инженер-техник, юл-төзелеш хәрби формированиеләрендә һәм гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итәргә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының коткару хәрби формированиеләрендә, Россия Федерациясенең Тышкы разведка хезмәтендә, федераль иминлек хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында һәм Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының мобилизация әзерлеген тәэмин итүче федераль органда солдатлар, матрослар, сержантлар, старшиналар биләргә тиешле хәрби вазыйфаларда контракт буенча кимендә өч ел хезмәт иткән һәм хәрби хезмәттән «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 ел, 28 март, ФЗ-53 нче Федераль законның 51 статьясындагы 1 нче пунктның «б» - «г» пунктчаларында, 2 нче пунктның «а» пунктчасында һәм 3 нче пунктның «а» - «в» пунктчаларында күздә тотылган нигезләр буенча азат ителгән гражданнар арасындагы студентларга билгеләнә. Дәүләт социаль стипендиясе шулай ук дәүләт социаль ярдәме алган студентларга бирелә. Дәүләт социаль стипендиясе студентлар күрсәтелгән категориясенә дәүләт социаль ярдәмен билгеләүне раслый торган документны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмага тапшырган көннән соң, әлеге дәүләт социаль ярдәмен билгеләгән көннән башлап бер елга билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\392.docx